КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 28 август г.Казань № 751

Татарстан Республикасының Әгерҗе, Актаныш, Минзәлә һәм Тукай муниципаль районнары территориясендә «Кама-Ык» комплекслы профильле төбәк әһәмиятендәге дәүләт табигый тыюлыгын төзү турында

«Аеруча саклаулы табигать территорияләре турында» 1995 елның 14 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль Закон, «Хайваннар дөньясы турында» 1995 елның 24 апрелендәге 52-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Су кодексы һәм Татарстан Республикасы Экология кодексы нигезендә, Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән табигый комплексларны, үсемлекләрнең һәм хайваннарның су һәм су асты төрләрен саклау, максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының Татарстан Республикасының Әгерҗе, Актаныш, Минзәлә һәм Тукай муниципаль районнары территориясендә 22 290,567 гектар мәйданлы «Кама-Ык» комплекслы профильле төбәк әһәмиятендәге дәүләт табигый тыюлыгын төзү турында тәкъдимне кабул итәргә.

2. Карарга теркәлгән түбәндәгеләрне расларга:

«Кама-Ык» комплекслы профильле төбәк әһәмиятендәге дәүләт табигый тыюлыгы турында нигезләмә;

«Кама-Ык» комплекслы профильле төбәк әһәмиятендәге дәүләт табигый тыюлыгы чикләренең урнашу урынының график тасвирламасы.

3. Территориаль планлаштыру документларын эшләгәндә «Кама-Ык» комплекслы профильле төбәк әһәмиятендәге дәүләт табигый тыюлыгының чикләре

җирләрен инвентаризацияләү үткәрүне һәм махсус саклау режимының үзенчәлекләрен исәпкә алырга.

4. Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетына:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Татарстан Республикасының махсус сакланыла торган табигать территорияләре дәүләт реестрына тиешле үзгәрешләр кертү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын тәкъдим итәргә;

финанслау бүлеп бирелгәннән соң ел дәвамында «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Федераль кадастр палатасы» федераль дәүләт бюджет учреждениесе филиалына «Кама-Ык» комплекслы профильле төбәк әһәмиятендәге дәүләт табигый тыюлыгы чикләре турында мәгълүматларны билгеләнгән тәртиптә тапшыруны тәэмин итәргә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры                                                                  А. В. Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 28 август, 751 нче
карары белән расланды

## «Кама-Ык» комплекслы профильле төбәк әһәмиятендәге дәүләт табигый тыюлыгын төзү турында турында нигезләмә

### 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. «Кама-Ык» комплекслы профильле төбәк әһәмиятендәге дәүләт табигый тыюлыгы (алга таба – тыюлык) Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән табигый комплексларны, үсемлекләрнең һәм хайваннарның су һәм су асты төрләрен саклау максатыннан оештырылган төбәк әһәмиятендәге аеруча саклаулы табигый территория булып тора.

Тыюлык Татарстан Республикасының Әгерҗе, Актаныш, Минзәлә һәм Тукай муниципаль районнары территориясендә урнашкан һәм гомуми мәйданы 22 290,567 гектар.

1.2. Тыюлык Татарстан Республикасының табигый-тыюлык фонды составына керә.

Тыюлыкның чикләре җирлектә махсус мәгълүмати билгеләр белән билгеләнә, анда тыюлыкны махсус саклау режимы һәм аның чикләре схемасы кыскача тасвирлана.

1.3. Тыюлык Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты (алга таба – Комитет) карамагында тора .

Комитет урнашкан урын: Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Кәрим Тинчурин ур., 29 йорт.

### 2. Тыюлык эшчәнлеген оештыру буенча комитетның төп бурычлары

2.1. Тыюлык эшчәнлеген оештырганда Комитетның төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

табигый комплексларны саклауны һәм торгызуны тәэмин итү;

биологик төрлелекне саклауны тәэмин итү;

хуҗалык һәм башка төр эшчәнлекнең әйләнә-тирәлеккә тискәре йогынтысын булдырмау;

төбәк әһәмиятендәге махсус сакланыла торган табигать территорияләре системасын үстерү һәм камилләштерү.

### 3. Тыюлык эшчәнлеген оештырганда комитет функцияләре

3.1. Комитет үзенә йөкләнгән бурычлар нигезендә тыюлык эшчәнлеген оештыру буенча түбәндәге төп функцияләрне башкара:

хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм яңадан торгызу белән идарә итү, хайваннар дөньясы объектларын куллануны тәртипкә салу;

төбәк әһәмиятендәге махсус сакланыла торган табигать территорияләрен оештыру һәм эшләтү өлкәсендә идарә, Татарстан Республикасының Кызыл китабын алып бару;

төбәк әһәмиятендәге махсус сакланыла торган табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге, табигый дәвалау ресурсларын, дәвалау-савыктыру урыннарын һәм курортларны санитар (тау-санитар) саклауны тәэмин итү өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген дә кертеп.

## 4. Тыюлыкны аерым саклау режимы

4.1. Тыюлык территориясен махсус саклау режимы (алга таба - махсус саклау режимы) тыюлыкны булдыру максатларыннан һәм әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендәге законнардан чыгып билгеләнә.

4.2. Тыюлык территориясендә тыюлыкның сакланышын бозуга китерә торган теләсә нинди эшчәнлек, шул исәптән түбәндәгеләр тыела:

торак пунктлар, яңа бакчачылык һәм яшелчәчелек коммерцияле булмаган ширкәтләре төзү;

шәхси торак төзелеше объектлары төзү, бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару, бакчачылык һәм яшелчәчелек коммерцияле булмаган ширкәтләре өчен җир кишәрлекләре бирү;

капиталь төзелеш объектларын, шул исәптән линияле объектларны төзү, әгәр мондый төзелеш тыюлыкның эшләве яки аның чикләрендә урнашкан торак пунктларның эшләвен тәэмин итү белән бәйле булмаса һәм әлеге Нигезләмәнең 4.3 пунктында каралган очраклардан тыш, җир кишәрлекләренең максатчан билгеләнешенә туры килмәсә;

агынты, шул исәптән дренаж суларны агызу;

механик транспорт чараларының йөрүе һәм туктавы, шулай ук уылдык чәчү чорында аз сыйдырышлы судноларның йөрүе һәм туктавы, печән әзерләү өчен файдаланыла торган транспорттан, тыюлыкны саклауны, махсус сакланыла торган табигать территорияләрен саклау һәм куллану өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыручы органнар, тыюлык чикләрендә вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы башка дәүләт органнары транспортыннан тыш, электр тапшыру линияләренә хезмәт күрсәтү чараларын башкару өчен махсус техникадан, шулай ук аварияләрне, табигый бәла-казаларны һәм гадәттән тыш характердагы башка хәлләрне бетерү буенча чаралар үткәрүне тәэмин итүче транспорттан, сәнәгый балыкчылыкны һәм ау хуҗалыгы килешүләре нигезендә хайваннар дөньясыннан файдалануны гамәлгә ашыручы юридик затларның (шәхси эшмәкәрләрнең) транспортыннан тыш;

автотранспорт чараларын һәм авыл хуҗалыгы техникасын юу;

моның өчен махсус каралган урыннардан читтә учаклар ягу;

агулы химикатлар, минераль ашламалар, үсемлекләрне саклау чаралары һәм үсеш стимуляторлары куллану, шулай ук агулы химикатлар, минераль ашламалар, тирес һәм ягулык-майлау материаллары урнаштыру һәм туплау;

җитештерү һәм куллану калдыкларын, радиоактив, химик, шартлаткыч, токсинлы, агулый торган һәм агулы матдәләрне урнаштыру объектларын булдыру;

җирле флора һәм фаунага ят булган үсемлекләрне утырту һәм хайваннарны күчерү;

язгы чорда аулау, язгы чорда санын җайга салу һәм фәнни-тикшеренү эшчәнлеген, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру максатларында аулаудан тыш;

Россия Федерациясенең Кызыл китабына һәм Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән төрләргә караган үсемлекләр, хайваннар һәм башка организмнарның санын киметә һәм аларның яшәү тирәлеген начарайта торган эшчәнлек;

аучылык объектларына кертелмәгән хайваннарны аулау, санын җайга салу максатларында аулаудан тыш, шулай ук Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм юкка чыгу куркынычы яный торган хайваннар, үсемлекләр һәм гөмбәләр төрләрен аулау һәм җыю;

ояларны, өннәрне, башка яшеренү урыннарын юк итү, шулай ук кыргый хайваннарны борчуга китерүче башка гамәлләр;

көпшәле агачларны юк итү;

кыргый үсемлекләр җимешләрен, җиләк-җимеш, чикләвек, гөмбә, орлыклар, каен согы әзерләү һәм дару үләннәре җыю, законнар белән билгеләнгән тәртиптә аларны шәхси ихтыяҗлар өчен әзерләү һәм җыюдан тыш;

урман янгыннарын кабызып җибәрү, үсемлек яндыру ;

туфракның уңдырышлылыгын киметә торган эшчәнлек;

файдалы казылмаларны эзләү, файдалы казылмалар ятмаларын эзләү һәм бәяләүне, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен җир асты байлыклары кишәрлекләрен геологик өйрәнүне һәм аларның яраклылыгын бәяләүне үз эченә алган геологик өйрәнүне үткәрү (бу эшләрне тыюлык булдырылганга кадәр бирелгән лицензияләр буенча җир асты байлыкларыннан файдалану шартлары нигезендә башкарудан тыш);

тыюлык территориясендә аншлагларны, шлагбаумнарны, стендларны, чик баганаларын һәм башка мәгълүмат билгеләрен һәм күрсәткечләрен, эшләнгән экологик сукмакларны, төзелмәләрне һәм корылмаларны бетерү һәм аларга зыян китерү, агачларга язулар һәм билгеләр төшерү;

табигать комплексының экологик тигезлеген боза торган, бу территориянең экологик кыйммәтен киметә, хайваннар һәм үсемлекләр дөньясының саклана торган объектларына һәм аларның яшәү тирәлегенә зыян китерә торган башка эшчәнлек төрләре.

4.3. Тыюлык территориясендә, Комитет белән килешеп, рөхсәт ителә:

гидромелиоратив һәм ирригация эшләрен үткәрү;

аучылык хуҗалыгы килешүләре нигезендә аучылык хуҗалыгын алып бару өчен социаль мөһим объектлар, аучылык инфраструктурасы объектлары, гидротехник корылмалар төзү ;

элек төзелгән линия объектларын реконструкцияләү, капиталь ремонтлау һәм ремонтлау, линияле объектларны, бүлеп бирелгән полосаларны һәм юл буе полосаларын карап тоту;

төбәк геологик өйрәнү;

экологик тернәкләндерү һәм рекультивация үткәрү, ;

Россия Федерациясенең Кызыл китабына һәм Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән төрләргә кертелгән үсемлекләрне, хайваннарны һәм башка организмнарны, шулай ук аларның яшәү тирәлеген саклау чараларын гамәлгә ашыру;

су объектларының яр буе саклау полосалары чикләрендә һәм хайваннар дөньясы объектларының яшәү тирәлеге буларак аеруча әһәмиятле булган кишәрлекләрдә камыш әзерләү һәм чабу;

үсемлекләрнең, хайваннарның һәм Россия Федерациясенең Кызыл китабына һәм Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән төрләргә караган башка организмнарның яшәү тирәлеген яхшыртуга ярдәм итүче профилактик чаралар үткәрү;

урман утыртмаларының сайланма яки тоташ кисүләрен, урманнарны саклау, яклау һәм яңадан торгызу чараларын үткәрү;

экологик туризмны гамәлгә ашыру;

торак сыйфатында (палатка шәһәрчекләре, кемпинглар, торак вагончиклар, торак прицеплар) куллануга яраклы корылмалар урнаштыру;

терлек көтү һәм су эчерү.

4.4. Углеводород чималын чыгару буенча гамәлдәге лицензияләрне гамәлгә ашыру кысаларында Комитет белән килешү буенча рөхсәт ителә:

геологик разведка һәм сейсмик разведка эшләрен үткәрү;

нефть һәм газ ятмаларын, табигый битумнарны проектлау, эшкәртү һәм төзекләндерү эшләрен үткәрү;

нефть инфраструктурасы объектларын төзү буенча эшләр башкару;

нефть чыгару объектларын капиталь ремонтлау, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү эшләрен башкару.

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторын раслау турында» 2014 ел, 1 сентябрь, 540 нчы боерыгы нигезендә тыюлык чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалануның түбәндәге төп төрләре рөхсәт ителә, әгәр алар әлеге Нигезләмәнең IV бүлеге таләпләренә каршы килмәсә:

умартачылык (Комитет белән килешү буенча) (1.12*)

күчмә торак (Комитет белән килешенеп) (2.4*)

фәнни тикшеренүләр үткәрү (Комитет белән килешү буенча) (3.9.2*);

табигый-танып-белү туризмы (Комитет белән килешү буенча) (5.2*);

ау һәм балык тоту (5.3* );

кече суднолар өчен причаллар (Комитет белән килешү буенча) (5.4*);

җир асты байлыкларыннан файдалану (тыюлык барлыкка килгәнче бирелгән җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияләр буенча гына) (6.1*);

табигать территорияләрен саклау (Комитет белән килешү буенча) (9.1*);

тарихи-мәдәни эшчәнлек (Комитет белән килешү буенча) (9.3* );

---

*Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторын раслау турында» 2014 ел, 1 сентябрь, 540 нче боерыгы белән расланган Җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторы буенча кодны билгеләү.

урман ресурсларын әзерләү (бары гражданнар гына үз ихтыяҗлары өчен) (10.3*);

резерв урманнар (Комитет белән килешү буенча) (10.4*);

су объектларыннан гомуми файдалану (11.1*);

гидротехник корылмалар (Комитет белән килешү буенча) (11.3*).

4.6. Тыюлык территориясендә рөхсәт ителгән хуҗалык эшчәнлеге тыюлыкны махсус саклау режимы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җитештерү процессларын башкарганда, шулай ук транспорт магистральләрен, труба үткәргечләрен, элемтә линияләрен һәм электр тапшыргыч линияләрен файдаланганда, хайваннар дөньясы объектларының һәлак булуын булдырмау таләпләрен раслау турында» 1996 ел, 13 август, 997 нче карары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җитештерү процессларын башкарганда, шулай ук транспорт магистральләрен, труба үткәргечләрен, элемтә линияләрен һәм электр тапшыргычларын кулланганда, хайваннар дөньясы объектларының һәлак булуын булдырмау буенча таләпләр турында» 2000 ел, 15 сентябрь, 669 нчы карары нигезендә тормышка ашырыла.

4.7. Әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендәге законнарны һәм тыюлык территориясендә урнашкан барлык табигатьтән файдаланучылар, шулай ук тыюлыкка ял итү, туризм һәм башка максатларда йөрүче затлар өчен аерым сак режимын үтәү мәҗбүри.

4.8. Тыюлыкның чикләре һәм махсус саклау режимының үзенчәлекләре территориаль планлаштыру документларын әзерләгәндә, урман хуҗалыгы регламентларын һәм урманнарны үзләштерү проектларын эшләгәндә, урман корылышы һәм җирләрне инвентаризацияләү вакытында исәпкә алына.

## 5. Рөхсәт ителгән төзелешнең иң чик максималь параметрлары, тыюлык территориясендә капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү

5.1. Тыюлык территориясендә рөхсәт ителгән төзелеш, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең иң чик максималь параметрлары:

биналарның, корылмаларның, төзелмәләрнең иң чик катлары - ике кат;

җир участогы чикләрендәге төзелеш проценты - 50 проценттан да артык түгел.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 28 август, 751 нче
карары белән расланды

## «Кама-Ык» комплекслы профильле төбәк әһәмиятендәге дәүләт табигый тыюлыгы чикләренең урнашу урынының график тасвирламасы

### 1 бүлек

| «Кама-Ык» комплекслы профильле төбәк әһәмиятендәге дәүләт табигый тыюлыгы турында турында мәгълүматлар | | |
|---|---|---|
| Т\с | Объектның тасвирнамәләре | Тасвирнамәләрнең тасвирламасы |
| 1. | Объектның урнашу урыны | Татарстан Республикасы, Әгерҗе, Актаныш, Минзәлә һәм Тукай муниципаль районнары |
| 2. | Объектның мәйданы +/- мәйданны билгеләү төгәлсезлеге зурлыгы (Р + / - Дельта)) | 222 905 670 кв.метр |
| 3. | Объектның башка тасвирнамәләре | - |

### 2 бүлек

| Объект чикләренең урнашу урыны турында мәгълүматлар | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. Координаталар системасы : МСК-16 | | | | | |
| 2. Объект чикләренең характерлы нокталары турында мәгълүматлар | | | | | |
| Чикләр-нең харак-терлы нокталарын билгеләү | Координатлар, метр | | Характерлы ноктаның координатларын билгеләү ысулы | Характерлы нокта урынының уртача квадрат төгәлсезлеге (Mt), метр | Җирлектә ноктаны билгеләү тасвирлама-сы (булганда) |
| | X | Y | | | |
| - | - | - | - | - | - |
| 3. Объект чиге өлешенең (өлешләренең) характерлы нокталары турында мәгълүматлар | | | | | |
| Чик өлеше-нең харак-терлы нокта-рын билгеләү | Координатлар, метр | | Характерлы ноктаның координатларын билгеләү ысулы | Характерлы нокта урынының уртача квадрат төгәлсезлеге (Mt), метр | Җирлектә ноктаны билгеләү тасвирламасы (булганда) |
| | X | Y | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1 өлеш | | | | | |
| 1 | 489763,083 | 2350660,096 | Картометрик | 5 | - |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 2 | 489887,68 | 2355210,243 | Картометрик | 5 | - |
| 3 | 489279,505 | 2357424,734 | Картометрик | 5 | - |
| 4 | 489049,873 | 2358324,168 | Картометрик | 5 | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| 5 | 488835,981 | 2358729,912 | Картометрик | 5 | - |
| 6 | 488407,619 | 2359165,524 | Картометрик | 5 | - |
| 7 | 488165,36 | 2359850,811 | Картометрик | 5 | - |
| 8 | 488165,668 | 2360275,014 | Картометрик | 5 | - |
| 9 | 487677,342 | 2361344,946 | Картометрик | 5 | - |
| 10 | 487157,717 | 2361765,967 | Картометрик | 5 | - |
| 11 | 486588,413 | 2362058,863 | Картометрик | 5 | - |
| 12 | 485959,895 | 2362723,278 | Картометрик | 5 | - |
| 13 | 485247,405 | 2363120,512 | Картометрик | 5 | - |
| 14 | 484746,122 | 2363337,573 | Картометрик | 5 | - |
| 15 | 483894,054 | 2364309,511 | Картометрик | 5 | - |
| 16 | 483085,938 | 2364407,299 | Картометрик | 5 | - |
| 17 | 483424,07 | 2366012,721 | Картометрик | 5 | - |
| 18 | 483354,382 | 2366771,726 | Картометрик | 5 | - |
| 19 | 482580,92 | 2368800,387 | Картометрик | 5 | - |
| 20 | 482334,442 | 2369476,594 | Картометрик | 5 | - |
| 21 | 482188,42 | 2370091,733 | Картометрик | 5 | - |
| 22 | 482049,489 | 2370246,241 | Картометрик | 5 | - |
| 23 | 481736,572 | 2370658,628 | Картометрик | 5 | - |
| 24 | 481628,448 | 2370993,778 | Картометрик | 5 | - |
| 25 | 481813,732 | 2371765,292 | Картометрик | 5 | - |
| 26 | 482038,642 | 2372433,944 | Картометрик | 5 | - |
| 27 | 482306,555 | 2373004,686 | Картометрик | 5 | - |
| 28 | 482516,072 | 2373673,465 | Картометрик | 5 | - |
| 29 | 482728,87 | 2374202,411 | Картометрик | 5 | - |
| 30 | 482713,613 | 2375128,7 | Картометрик | 5 | - |
| 31 | 482781,522 | 2376213,942 | Картометрик | 5 | - |
| 32 | 482710,364 | 2377040,989 | Картометрик | 5 | - |
| 33 | 482717,51 | 2378312,152 | Картометрик | 5 | - |
| 34 | 482664,538 | 2378647,071 | Картометрик | 5 | - |
| 35 | 482639,759 | 2379061,062 | Картометрик | 5 | - |
| 36 | 482509,015 | 2379585,4 | Картометрик | 5 | - |
| 37 | 482265,712 | 2380041,665 | Картометрик | 5 | - |
| 38 | 482186,299 | 2380984,364 | Картометрик | 5 | - |
| 39 | 482079,486 | 2381287,786 | Картометрик | 5 | - |
| 40 | 482084,324 | 2381545,886 | Картометрик | 5 | - |
| 41 | 482218,129 | 2382086,687 | Картометрик | 5 | - |
| 42 | 482639,753 | 2383116,373 | Картометрик | 5 | - |
| 43 | 483231,835 | 2384594,92 | Картометрик | 5 | - |
| 44 | 483312,88 | 2384867,131 | Картометрик | 5 | - |
| 45 | 482903,139 | 2385326,906 | Картометрик | 5 | - |
| 46 | 482825,153 | 2385721,315 | Картометрик | 5 | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| 47 | 482921,756 | 2386381,083 | Картометрик | 5 | - |
| 48 | 482942,11 | 2386843,1 | Картометрик | 5 | - |
| 49 | 483310,595 | 2387556,249 | Картометрик | 5 | - |
| 50 | 482347,69 | 2386913,896 | Картометрик | 5 | - |
| 51 | 481756,53 | 2386366,658 | Картометрик | 5 | - |
| 52 | 481152,075 | 2385366,956 | Картометрик | 5 | - |
| 53 | 481110,091 | 2384872,576 | Картометрик | 5 | - |
| 54 | 480969,094 | 2384552,498 | Картометрик | 5 | - |
| 55 | 480407,099 | 2384057,496 | Картометрик | 5 | - |
| 56 | 479617,005 | 2383163,56 | Картометрик | 5 | - |
| 57 | 479557,318 | 2382895,697 | Картометрик | 5 | - |
| 58 | 478743,175 | 2382130,401 | Картометрик | 5 | - |
| 59 | 478075,412 | 2381502,584 | Картометрик | 5 | - |
| 60 | 477466,158 | 2380781,894 | Картометрик | 5 | - |
| 61 | 476805,598 | 2379625,259 | Картометрик | 5 | - |
| 62 | 476040,369 | 2379860,155 | Картометрик | 5 | - |
| 63 | 475779,813 | 2379983,547 | Картометрик | 5 | - |
| 64 | 474702,934 | 2379863,35 | Картометрик | 5 | - |
| 65 | 474369,838 | 2379917,798 | Картометрик | 5 | - |
| 66 | 474007,947 | 2380102,116 | Картометрик | 5 | - |
| 67 | 473953,012 | 2380324,126 | Картометрик | 5 | - |
| 68 | 473858,045 | 2380428,218 | Картометрик | 5 | - |
| 69 | 472945,546 | 2380526,077 | Картометрик | 5 | - |
| 70 | 472481,046 | 2380399,63 | Картометрик | 5 | - |
| 71 | 472281,579 | 2380090,526 | Картометрик | 5 | - |
| 72 | 471955,665 | 2379929,433 | Картометрик | 5 | - |
| 73 | 471697,597 | 2379336,156 | Картометрик | 5 | - |
| 74 | 471725,465 | 2379092,552 | Картометрик | 5 | - |
| 75 | 472343,172 | 2378456,42 | Картометрик | 5 | - |
| 76 | 472772,845 | 2378135,941 | Картометрик | 5 | - |
| 77 | 473485,942 | 2377470,773 | Картометрик | 5 | - |
| 78 | 473829,086 | 2377416,326 | Картометрик | 5 | - |
| 79 | 473622,705 | 2378206,719 | Картометрик | 5 | - |
| 80 | 473941,019 | 2378567,658 | Картометрик | 5 | - |
| 81 | 474359,367 | 2378484,778 | Картометрик | 5 | - |
| 82 | 474603,56 | 2378932,976 | Картометрик | 5 | - |
| 83 | 475165,689 | 2379041,414 | Картометрик | 5 | - |
| 84 | 475268,163 | 2378796,656 | Картометрик | 5 | - |
| 85 | 475486,581 | 2378372,832 | Картометрик | 5 | - |
| 86 | 475384,979 | 2378110,432 | Картометрик | 5 | - |
| 87 | 475378,161 | 2377103,227 | Картометрик | 5 | - |
| 88 | 475299,196 | 2376032,645 | Картометрик | 5 | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| 89 | 475157,824 | 2375588,235 | Картометрик | 5 | - |
| 90 | 475317,922 | 2375508,886 | Картометрик | 5 | - |
| 91 | 475543,794 | 2374917,554 | Картометрик | 5 | - |
| 92 | 475496,301 | 2374681,145 | Картометрик | 5 | - |
| 93 | 475443,151 | 2374046,936 | Картометрик | 5 | - |
| 94 | 475736,904 | 2373308,971 | Картометрик | 5 | - |
| 95 | 476096,399 | 2373098,356 | Картометрик | 5 | - |
| 96 | 476360,814 | 2372528,585 | Картометрик | 5 | - |
| 97 | 476368,401 | 2371844,547 | Картометрик | 5 | - |
| 98 | 476670,216 | 2371236,638 | Картометрик | 5 | - |
| 99 | 477083,915 | 2370655,858 | Картометрик | 5 | - |
| 100 | 477588,526 | 2369420,128 | Картометрик | 5 | - |
| 101 | 477900,512 | 2367736,134 | Картометрик | 5 | - |
| 102 | 478692,973 | 2364785,33 | Картометрик | 5 | - |
| 103 | 478316,167 | 2364004,535 | Картометрик | 5 | - |
| 104 | 476340,205 | 2362590,588 | Картометрик | 5 | - |
| 105 | 475160,988 | 2362047,754 | Картометрик | 5 | - |
| 106 | 473885,314 | 2360815,464 | Картометрик | 5 | - |
| 107 | 473846,588 | 2360352,73 | Картометрик | 5 | - |
| 108 | 476443,55 | 2360607,856 | Картометрик | 5 | - |
| 109 | 478673,967 | 2361243,982 | Картометрик | 5 | - |
| 110 | 479817,298 | 2360747,693 | Картометрик | 5 | - |
| 111 | 480719,371 | 2359952,906 | Картометрик | 5 | - |
| 112 | 481844,434 | 2360222,488 | Картометрик | 5 | - |
| 113 | 482612,145 | 2360895,963 | Картометрик | 5 | - |
| 114 | 483682,073 | 2360882,219 | Картометрик | 5 | - |
| 115 | 483525,661 | 2357156,442 | Картометрик | 5 | - |
| 116 | 483595,576 | 2356457,178 | Картометрик | 5 | - |
| 117 | 481692,192 | 2356514,496 | Картометрик | 5 | - |
| 118 | 480647,939 | 2356274,869 | Картометрик | 5 | - |
| 119 | 480241,86 | 2356043,821 | Картометрик | 5 | - |
| 120 | 480011,152 | 2355680,725 | Картометрик | 5 | - |
| 121 | 480181,38 | 2355495,518 | Картометрик | 5 | - |
| 122 | 483366,538 | 2355271,974 | Картометрик | 5 | - |
| 123 | 484295,563 | 2354948,302 | Картометрик | 5 | - |
| 124 | 484951,38 | 2353698,426 | Картометрик | 5 | - |
| 125 | 484871,619 | 2353006,925 | Картометрик | 5 | - |
| 126 | 485245,698 | 2352359,394 | Картометрик | 5 | - |
| 127 | 484858,335 | 2351439,294 | Картометрик | 5 | - |
| 128 | 483514,592 | 2349251,254 | Картометрик | 5 | - |
| 129 | 483951,861 | 2348128,474 | Картометрик | 5 | - |
| 130 | 484758,566 | 2347366,952 | Картометрик | 5 | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| 131 | 485336,578 | 2347274,883 | Картометрик | 5 | - |
| 132 | 486039,616 | 2348921,557 | Картометрик | 5 | - |
| 133 | 486282,033 | 2350831,576 | Картометрик | 5 | - |
| 134 | 488434,091 | 2348763,825 | Картометрик | 5 | - |
| 1 | 489763,083 | 2350660,096 | Картометрик | 5 | - |


## 3 бүлек

| Объектның үзгәртелгән (тәгаенләнгән) чикләренең урнашу урыны турында мәгълүматлар | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. Координатлар системасы | | | | | | | |
| 2. Объект чикләренең характерлы нокталары турында мәгълүматлар | | | | | | | |
| Чикләрнең характерлы нокталарын билгеләү | Гамәлдәге координатлар, метр | | Үзгәртелгән (тәгаенләнгән) координатлар, метр | | Характерлы ноктаның координат-ларын билгеләү ысулы | Характерлы нокта урынының уртача квадрат төгәлсезлеге (Mt), метр | Җирлектә ноктаны билгеләү тасвирла-масы (булганда) |
| | X | Y | X | Y | | | |
| - | - | - | - | - | - | - | - |
| 3. Объект чиге өлешенең (өлешләренең) характерлы нокталары турында мәгълүматлар | | | | | | | |
| - | - | - | - | - | - | - | - |

4 бүлек

"Кама-Ык» төбәк әһәмиятендәге комплекслы профильле дәүләт табигать тыюлыгы" объекты чикләре планы

Чикләрнең күзәтү схемасы




Масштабы 1 : 100 000

Файдаланылган шартлы билгеләр һәм тамгалар:

**1** – чикнең характерлы ноктасы;

– объектның чиге;


– Татарстан Республикасы чиге .

.

4 бүлек

"Кама-Ык» төбәк әһәмиятендәге комплекслы профильле дәүләт табигать тыюлыгы" объекты чикләре планы

1 нче бит




Масштабы 1 : 65 000

Файдаланылган шартлы билгеләр һәм тамгалар:

**1** – чикнеӊ характерлы ноктасы;


– объектныӊ чиге;

– Татарстан Республикасы чиге .

4 бүлек

"Кама-Ык» төбәк әһәмиятендәге комплексчы профильле дәүләт табигать тыюлыгы" объекты чикләре планы

2 нче бит




Масштабы 1 : 65 000

Файдаланылган шартлы билгеләр һәм тамгалар:

**1** – чикнең характерлы ноктасы;

– объектның чиге;

– Татарстан Республикасы чиге .